КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 28 декабрь г.Казань № б-2924

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең демографик сәясәтен тормышка ашыру буенча чаралар турында» 2012 елның 7 маендагы 606 номерлы Указын, Россия Федерациясе Президентының 2007 елның 9 октябрендәге 1351 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе демографик сәясәте концепциясен, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 25 августындагы б-1618 номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә дәүләт гаилә сәясәте концепциясен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы карары белән расланган 2010 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге перспективага Татарстан Республикасын демографик үстерүнең комплекслы программасын һәм Татарстан Республикасы территориясендә гаилә һәм демографик сәясәт өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру максатларында:

1. Түбәндәгеләрне (боерыкка теркәләләр) расларга:

2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасында гаилә һәм демография сәясәтен тормышка ашыру чаралары планын (алга таба – Чаралар планы);

2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасында гаилә һәм демография сәясәтен торымшка ашыру чаралары планы үтәлеше турындагы хисап формасын.

2. Чаралар планын тормышка ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы Законында каралган акча чикләрендә Чаралар планын үтәүне һәм Чаралар планында каралган индикаторларга ирешүне тәэмин итәргә;

елга ике тапкыр (15 июльгә кадәр – агымдагы елның беренче яртыеллыгы йомгаклары буенча һәм хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр) бу боерык белән расланган форма буенча Чаралар планы үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

3. Федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, шулай ук Чаралар планында күрсәтелгән оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Чаралар планын тормышка ашыруда катнашуны;

елга ике тапкыр (15 июльгә кадәр – агымдагы елның беренче яртыеллыгы йомгаклары буенча һәм хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр) бу боерык белән расланган форма буенча Чаралар планы үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертүне.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, Чаралар планында күрсәтелгән оешмалар тарафыннан бирелә торган мәгълүматны җыюны гамәлгә ашырырга һәм елга ике тапкыр (25 июльгә кадәр – агымдагы елның беренче яртыеллыгы йомгаклары буенча һәм хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварына кадәр) гомуми мәгълүматны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 28 декабрь, б-2924 нче
боерыгы белән расланды

Форма

___________________________________________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлекчәсе, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органы, иҗтимагый оешма исеме)

20__ елның ______________ өчен 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасында гаилә һәм демография сәясәтен тормышка ашыру чаралары планы үтәлеше турында хисап формасы

| Т/с | 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасында гаилә һәм демография сәясәтен тормышка ашыру чаралары планын чаралары исеме | План индикаторы | Хисап чорында ирешелгән индикаторның факттагы күрсәткече (Татарстан Республикасы буенча һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре яктылыгында) | 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасында гаилә һәм демография сәясәтен тормышка ашыру чаралары планы (шул исәптән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре киселешендә) үтәлеше буенча текст рәвешендә җентекле мәгълүмат | Искәрмәләр (индикаторның план күрсәткеченә ирешмәгән очракта аңлатмалар) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

___________________________________________